ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 86 (I өлеш) № 92 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$11^1$ статья. **Татарстан Республикасында сатып алуларны оештыру**

«Татарстанның медицина техникасы һәм фармациясе» дәүләт унитар предприятиесе бердәнбер тәэмин итүче (башкаручы) буларак Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органын, аңа ведомство буйсынуындагы оешмаларны дарулар, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, медицина әйберләре, чыгым материаллары, дезинфекция чаралары, шулай ук тиешле товарларны саклау һәм илтеп тапшыру хезмәтләре, медицина әйберләрен ремонтлау һәм аларга техник хезмәт күрсәтү эшләре белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 14 июнь
№ 41-ТРЗ